| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 9 август г.Казань № 649

2018 – 2021 елларга Татарстан Республикасында наноиндустрияне үстерү буенча чаралар планын раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану хакында

Татарстан Республикасы икътисадын инновацион үстерү, икътисадның реаль секторына алдынгы технологияләрне кертү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2018 – 2021 елларга Татарстан Республикасында наноиндустрияне үстерү буенча чаралар планын (алга таба – Чаралар планы) расларга.

2. Чаралар планын тормышка ашыру өчен җаваплы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына аның үтәлешен тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, Чаралар планын тормышка ашыруда катнашучы сәнәгать предприятиеләренә, югары белем бирүче мәгариф оешмаларына һәм фәнни-тикшеренү оешмаларына ел саен, 1 февральгә кадәр, Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына аны үтәүнең барышы турында мәгълүмат кертергә.

4. Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына ел саен, 1 мартка кадәр, Чаралар планын үтәүнең барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына хисап кертергә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасында нанотехнологияләр өлкәсендә инновацион территориаль кластер булдыру чаралары планын раслау турында» 2014 ел, 15 декабрь, 989 нчы;

«2013 – 2016 елларга Татарстан Республикасында наноиндустрияне үстерү» озак вакытлы максатчан программасын раслау турында» 2013 ел, 9 апрель, 241 нче.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин